МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ __501/о_______

П Р И К А З　　　　　　　　　　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

«__28__»______04________2025__

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Түбән Суыксу авыл җирлеге генераль планы проектын әзерләү турында» 2024 елның 19 мартындагы 46/о номерлы боерыгы нигезендә, 2024 елның 15 ноябреннән 2024 елның 29 ноябренә кадәр уздырылган гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм аларның нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне исәпкә алып, боерык бирәм:

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең кушымтада бирелә торган генераль планын расларга.

2. Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсенең Кама агломерациясен үстерү бүлегенә (В.В.Бельскийга) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

«Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына торак пунктлар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең

координаталары исемлеге булган торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләрне әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып биш эш көне эчендә электрон рәвештә җибәрүне;

әлеге боерыкны Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында аны бастырып чыгару датасыннан 10 календарь көннән артмаган чорда урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н.Кудряшев

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрлыгының
28.04.2025 ел, №501/о боерыгы
белән расланды

# Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
# Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы

## СОСТАВЫ

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы

| т/с | Атамасы | Бит/битләр № |
|---|---|---|
| | | |
| **1 том Генераль план** | | |
| | Текст материаллары | |
| 1 | Территориаль планлаштыру турында нигезләмә | 18 |
| | График материаллар | |
| 2 | Җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы М1:10000 | 1/1 |
| 3 | Торак пунктлар чикләре картасы (шул исәптән төзелеп килүче торак пунктлар чикләре картасы) М1:10000 | 2/1 |
| 4 | Функциональ зоналар картасы М1:10000 | 3/1 |
| | Кушымта | |
| 5 | Торак пунктлар чикләре турында белешмәләр (китерелми) | 35 |
| | | |
| **2 Том Генераль планны нигезләү буенча материаллар (китерелми)** | | |
| | Текст материаллары | |
| 1 | Аңлатма язуы | 86 |
| 2 | Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм территорияне инженерлык әзерлеге буенча чаралар, гражданнар оборонасы буенча чаралар, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чаралар исемлеге. Аңлатма язуы | 190 |
| | График материаллар | |
| 3 | Җирлек территориясеннән хәзерге заман файдалану картасы М1:10000 | 1/1 |
| 4 | Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр, гражданнар оборонасы чаралары картасы М1:10000 | 2/1 |
| 5 | Инженерлык инфраструктурасы картасы М1:10000 | 3/1 |
| 6 | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (гамәлдәге урыны) М1:10000 | 4/1 |
| 7 | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (проект тәкъдиме) М1:10000 | 5/1 |

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ

**1 Том Генераль план Территориаль планлаштыру турында нигезләмә**

**Казан, 2025**

# ЭЧТӘЛЕК

*МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН............*

**1. КЕРЕШ........................................................................................................................................**

**2. Урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларның төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары, аларның урнашу урыны, шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә...........................**

**3. Функциональ зоналарның параметрлары, шулай ук аларда урнаштыру өчен планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектлар, региональ әһәмияттәге объектлар, җирле әһәмияттәге объектлар турында белешмәләр, линия объектларыннан тыш...........................................................................................................13**

**4. Муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителгән очракта территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристика................................18**

# 1. КЕРЕШ

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы (алга таба – Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 19.03.2024 ел, № 46/0 боерыгы нигезендә «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ тарафыннан эшләнде.

Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы аны гамәлгә ашыруның түбәндәге вакытлы срокларына әзерләнде:

Генераль планны гамәлгә ашыру буенча беренче чираттагы чаралар билгеләнгән беренче чират – 2031 елга кадәр.

Генераль планның барлык төп проект карарлары планлаштырылган исәпләмә чор – 2046 елга кадәр.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясы нигезендә Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

территориаль планлаштыру турында нигезләмә;

җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы;

торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре) картасы;

функциональ зоналар картасы.

Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планына аны нигезләү материаллары текст һәм карта рәвешендә кушып бирелә (китерелми).

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җирлекнең җирле әһәмияттәге чаралары расланырга тиеш.

Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планын эшләгәндә кулланылган материаллар:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 19 мартындагы 384-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Федераль транспорт (тимер юл, һава, диңгез, эчке су транспорты) һәм федераль әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәсендә Россия Федерациясен территориаль планлаштыру схемасы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 06.05.2015 ел, № 816-р күрсәтмәсе белән расланган Федераль транспорт өлкәсендә Россия Федерациясен территориаль планлаштыру схемасы (торба үткәргеч транспорты өлешендә);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 1 августындагы 1634-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Энергетика өлкәсендә Россия Федерациясен территориаль планлаштыру схемасы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 28 декабрендәге 2607-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясен территориаль планлаштыру схемасы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 26 февралендәге 247 номерлы күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясенең югары белем бирү өлкәсендәге территориаль планлаштыру схемасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 февралендәге 134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы советының 2012 елның 27 декабрендәге 18/7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы һәм аның составына керүче Түбән Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган рәсми белешмәләр.

## 2. Урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларның төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары, аларның урнашу урыны, шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә

| т/с | Объектның исеме | Урнашу урыны | Чараның төре | Төп характеристикалар | Гамәлгә ашыру сроклары | | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар | Функциональ зона исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Беренче чират | Хисап срогы | | |
| 1 | Социаль инфраструктура объектлары | | | | | | | |
| 1.1 | Балалар бакчасы | Югары Суыксу авылы | Яңа төзелеш | 40 урын | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.2 | Гомуми белем бирү мәктәбе | Түбән Суыксу авылы | Яңа төзелеш | 1,5 мең кв.м | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.3 | Фельдшер-акушерлык пункты | Түбән Суыксу авылы | Ликвидация | Сменага 20 кеше килә | + | - | билгеләнми | - |
| 1.4 | Фельдшер-акушерлык пункты | Түбән Суыксу авылы | Яңа төзелеш | Сменага 20 кеше килә | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.5 | Фельдшер-акушерлык пункты | Куады авылы | Яңа төзелеш | Сменага 17 кеше килә | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.6 | Авыл клубы | Югары Суыксу авылы | Ликвидация | 150 урын | + | - | билгеләнми | - |
| 1.7 | Авыл клубы | Югары Суыксу авылы | Яңа төзелеш | 150 урын | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.8 | Авыл клубы | Яңа Мусабай авылы | Яңа төзелеш | 150 урын | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.9 | Авыл клубы составындагы китапханә | Яңа Мусабай авылы | Яңа төзелеш | 0,4 мең берәмлек | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |

| т/с | Объектның исеме | Урнашу урыны | Чараның төре | Төп характеристикалар | Гамәлгә ашыру сроклары | | Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар | Функциональ зона исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Беренче чират | Хисап срогы | | |
| 1.10 | Иҗтимагый үзәк составындагы тамаша залы | Түбән Суыксу авылы | Яңа төзелеш | 290 урын | + | - | билгеләнми | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона |
| 1.11 | Балалар спорт мәйданчыгы | Түбән Суыксу авылы | Яңа төзелеш | 80 кв.м | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 1.12 | Полициянең терәк пункты | Түбән Суыксу авылы | Яңа төзелеш | 1 объект | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| **2** | **Транспорт инфраструктурасы объектлары** | | | | | | | |
| 2.1 | Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары | Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге | Яңа төзелеш (асфальт-бетон өслек җәю) | 13,3 км | + | - | билгеләнми | - |
| 2.2 | Урам-юл челтәре | Түбән Суыксу ав., Югары Суыксу ав., Куады ав., Яңа Мусабай ав., Керәшен Маҗыны ав. | Реконструкция (асфальт-бетон өслек җәю) | 32,3 км | + | - | билгеләнми | - |
| **3** | **Инженерлык инфраструктурасы объектлары** | | | | | | | |
| Су белән тәэмин итү объектлары | | | | | | | | |
| 3.1 | Су белән тәэмин итү челтәрләре | Түбән Суыксу ав., Югары Суыксу ав., Куады ав. | Яңа төзелеш | Объектка проект документациясен эшләү этабында билгеләнәчәкләр | + | + | санитар саклык полосасы диаметрына карап кимендә 10 м | - |
| 3.2 | Су белән тәэмин итү челтәрләре | Түбән Суыксу ав., Югары Суыксу ав., Куады ав. | Реконструкция | 10 км | + | + | санитар саклык полосасы диаметрына карап кимендә 10 м | - |

| т/с | Объектның исеме | Урнашу урыны | Чараның төре | Төп характерис-тикалар | Гамәлгә ашыру сроклары | | Территориядән файдаланунның махсус шартлары булган зоналар | Функциональ зона исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Беренче чират | Хисап срогы | | |
| 3.3 | Артезиан скважинасы һәм суэтем манарасы | Түбән Суыксу авылы | Ликвидация | 3 объект | + | + | гидродинамик исәпләүләр буенча 3 пояс составында санитар саклык зоналары. 1 пояс – 50 м. | - |
| 3.4 | Су күтәрү манарасы | Куады авылы | Реконструкция | 1 объект | + | + | 1пояс – 10м | Инженерлык инфраструктурасы |
| Су чыгару объектлары | | | | | | | | |
| 3.5 | Автоном канализация системасы | Түбән Суыксу ав., Югары Суыксу ав., Куады ав., Яңа Мусабай ав. | Яңа төзелеш | Объектка проект документациясе н эшләү этабында билгеләнәчәкләр | + | + | билгеләнми | - |
| 3.6 | Су чыгару челтәрләре | Түбән Суыксу ав., Югары Суыксу ав., Куады ав. | Реконструкция | 3 км | + | + | билгеләнми | - |
| Җылылык белән тәэмин итү объектлары | | | | | | | | |
| 3.7 | Балалар бакчасы өчен блок-модульле котельный | Югары Суыксу авылы | Яңа төзелеш | Объектка проект документациясе н эшләү этабында билгеләнәчәкләр | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 3.8 | Гомуми белем бирү мәктәбе өчен блок-модульле котельный | Түбән Суыксу авылы | Яңа төзелеш | | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 3.9 | Фельдшер-акушерлык пункты өчен блок-модульле котельный | Түбән Суыксу авылы | Яңа төзелеш | | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 3.10 | Авыл клубы өчен блок-модульле котельный | Югары Суыксу авылы | Яңа төзелеш | | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |

| т/с | Объектның исеме | Урнашу урыны | Чараның төре | Төп характеристикалар | Гамәлгә ашыру сроклары | | Территориядән файдаланунның махсус шартлары булган зоналар | Функциональ зона исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Беренче чират | Хисап срогы | | |
| 3.11 | Авыл клубы өчен блок-модульле котельный | Яңа Мусабай авылы | Яңа төзелеш | | + | - | билгеләнми | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы |
| 3.12 | Иҗтимагый үзәк өчен блок-модульле котельный | Югары Суыксу авылы | Яңа төзелеш | | + | - | билгеләнми | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона |
| 3.13 | Иҗтимагый үзәк өчен блок-модульле котельный | Түбән Суыксу авылы | Яңа төзелеш | | + | - | билгеләнми | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона |
| Газ белән тәэмин итү объектлары | | | | | | | | |
| 3.14 | Газны редукцияләү пункты | Югары Суыксу, Түбән Суыксу ав. | Яңа төзелеш | Объектка проект документациясен эшләү этабында билгеләнәчәкләр | + | - | Саклык зонасы – 10 м. | Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы |
| 3.15 | Газ белән тәэмин итү челтәрләре | Югары Суыксу, Түбән Суыксу ав. | Яңа төзелеш | | + | - | Саклык зонасы – 2 м. | - |
| Электр белән тәэмин итү объектлары | | | | | | | | |
| 3.16 | Трансформатор подстанциясе | Югары Суыксу, Түбән Суыксу ав. | Яңа төзелеш | Объектка проект документациясен эшләү этабында билгеләнәчәкләр | + | - | Саклык зонасы – 10 м. | Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы |
| 3.17 | Электр тапшыру линияләре | Югары Суыксу, Түбән Суыксу ав. | Яңа төзелеш | | + | - | Саклык зонасы – 2 м. | - |

## 3. Функциональ зоналарның параметрлары, шулай ук аларда урнаштыру өчен планлаштырыла торган федераль әһәмияттәге объектлар, региональ әһәмияттәге объектлар, җирле әһәмияттәге объектлар турында белешмәләр, линия объектларыннан тыш

3.1 нче таблица

| Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны планлаштырып үстерү параметрлары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Халыкның максималь тыгызлыгы, кеше / га | Даими халык саны, кеше. | Торак белән уртача тәэмин ителеш, м2/кеше. | Торакны файдалануга тапшыруның планлаштырылган күләме, м2 | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
| 701010101 | Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | планлаштырыла торган | 20,9 | 1212 | 50 | 60590 | 58,0290 | Газны редукцияләү пункты, трансформатор подстанциясе |

3.2 нче таблица

| т/с | Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны билгеләүнең тасвирламасы | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 701010101 | Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | планлаштырыла торган | Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы күбесенчә индивидуаль торак йортлар, блоктан торак йортлар һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә һәм мәдәни-көнкүреш, коммуналь, социаль хезмәт күрсәтүнең беренчел баскычында, шулай ук тиешле инженерлык һәм транспорт инфраструктурасында тиешле объектлар төзү өчен каралган. | 3.1 нче таблицаны карагыз | |
| | | | гамәлдәге | | 361,5736 | - |
| 2 | 701010102 | Азкатлы торак йортлар төзү зонасы (4 катка кадәр, мансарданы да кертеп) | гамәлдәге | Азкатлы торак йортлар (мансардасын да кертеп, 4 катка кадәр биеклектәге күпфатирлы йортлар), блоктан төзелеш йортлары, индивидуаль торак йортлар һәм мәдәни-көнкүреш, коммуналь һәм социаль хезмәт күрсәтүнең беренчел баскычындагы янәшәдәге, шулай ук янәшәдәге инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы төзү өчен каралган объектлар | 2,7055 | - |

| т/с | Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны билгеләүнең тасвирламасы | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | 70101030 1 | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона | планлаштырыла торган | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасының янәшәдәге объектларын урнаштырып, эшлекле, иҗтимагый, коммерция һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, шулай ук җитештерү һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектлар төзү өчен каралган объектлар | 0,4228 | Иҗтимагый үзәк составындагы тамаша залы, иҗтимагый үзәк өчен блок-модульле котельный |
| | | | гамәлдәге | | 1,1007 | - |
| 4 | 70101030 2 | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы | гамәлдәге | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, гомуми белем бирү оешмаларының, өстәмә белем бирү оешмаларының аерым объектлары, һөнәри һәм югары белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы объектлар, девиант тәртипле укучылар өчен махсус укыту-тәрбия учреждениеләре объектлары, фәнни оешмалар, мәдәният һәм сәнгать, сәламәтлек саклау, социаль билгеләнештәге объектлар, физик культура һәм массакүләм спорт объектлары, янәшәдәге объектларны урнаштырып, гыйбадәт йортлары һәм корылмаларын инженерлык һәм транспорт белән тәэмин итүне дә кертеп, башлыча социаль билгеләнештәге объектлар төзү өчен билгеләнгән | 7,9429 | |
| | | | планлаштырыла торган | | 2,4938 | Балалар бакчасы, гомуми белем бирү мәктәбе, авыл клублары, фельдшер-акушерлык пунктлары, авыл клубы составындагы китапханә, балалар спорт мәйданчыгы, полиция терәк пункты, балалар бакчасы өчен блок-модульле котельный Гомуми белем бирү мәктәбе өчен блок-модульле котельный Фельдшер-акушерлык пункты өчен блок-модульле котельный Авыл клублары өчен блок-модульле котельныйлар |
| 5 | 70101040 1 | Җитештерү зонасы | гамәлдәге | Җитештерү зонасы күбесенчә җитештерү предприятиеләрен, инженерлык һәм транспорт | 133,7072 | - |

| т/с | Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны билгеләүнең тасвирламасы | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | планлаштырыла торган | инфраструктурасын, шулай ук сәнәгый зоналарда урнашырга рөхсәт ителә торган коммерция объектларын урнаштыру өчен каралган. | 13,4662 | - |
| 6 | 70101040 2 | Коммуналь-склад зонасы | планлаштырыла торган | Йөкләрне вакытлыча саклау, бүлү һәм күчереп төяү (стратегик запасларны саклаудан тыш) билгеләнеше булган, йөк төзелгән җитештерү комплексларының өлешләре булмаган корылмаларны урнаштыру: сәнәгать базалары, складлар | 15,5374 | - |
| 7 | 70101060 2 | Ял итү зонасы | гамәлдәге | Балаларны савыктыру учреждениеләрен, савыктыру-спорт лагерьларын, пляжларны һәм ял һәм туризмның башка объектларын, шулай ук инженерлык һәм транспорт (парковка) инфраструктурасының янәшәдәге объектларын, мәдәни-көнкүреш хезмәт күрсәтүнең беренчел баскычы объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән | 1,1576 | - |
| 8 | 70101040 4 | Инженерлык инфраструктурасы зонасы | планлаштырыла торган | Инженерлык инфраструктурасы зонасы башлыча су белән тәэмин итү объектларын, су агызу объектларын, җылылык белән тәэмин итү объектларын, газ белән тәэмин итү объектларын, электр белән тәэмин итү объектларын, элемтә объектларын, башка төр инженерлык инфраструктурасын, шул исәптән коммуникацияләрне үткәрү коридорларын урнаштыру өчен каралган | 0,4469 | Су күтәрү манарасы |
| | | | гамәлдәге | | 1,5731 | - |
| 9 | 70101040 5 | Транспорт инфраструктурасы зонасы | гамәлдәге | Транспорт инфраструктурасы зонасы башлыча автомобиль транспорты объектларын, тимер юл транспорты объектларын, һава транспорты объектларын, су транспорты объектларын, торба үткәргеч транспорты объектларын, башка төр транспорт инфраструктурасы объектларын, урам-юл челтәре объектларын һәм аларга бәйле объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән | 96,2933 | - |
| | | | планлаштырыла торган | | 0,2121 | |
| 10 | 70101050 1 | Авыл хуҗалыгы җирләре зонасы | планлаштырыла торган | Авыл хуҗалыгы җирләре зонасы авыл хуҗалыгы җирләрендә авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүгә бәйле хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру; авыл хуҗалыгы терлекләрен көтүлек итү өчен каралган. | 12,9890 | - |
| | | | гамәлдәге | | 5806,3167 | |

| т/с | Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны билгеләүнең тасвирламасы | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 11 | 70101050 2 | Бакчачылык, яшелчәчелек зонасы | гамәлдәге | Бакчачылык, коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, яшелчәчелекне урнаштыру өчен, шулай ук янәшәдәге инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын, мәдәни-көнкүреш хезмәтенең беренчел баскычы объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән | 1,3418 | - |
| 12 | 70101050 4 | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге башка зоналар | гамәлдәге | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге башка зоналар фәнни-тикшеренү, укыту һәм авыл хуҗалыгы җитештерүенә бәйле башка объектлар өчен билгеләнгән крестьян-фермер хуҗалыкларын, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, аквакультура (балыкчылык) объектларын урнаштыру өчен каралган | 3,5661 | - |
| 13 | 70101050 3 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең җитештерү зонасы | планлаштырыла торган | Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең җитештерү зонасы авыл хуҗалыгы җитештерүе объектларын, агросәнәгать комплексына хезмәт күрсәтү объектларын, шулай ук инженерлык һәм транспорт инфраструктурасының янәшәдәге объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән | 31,2323 | - |
| | | | гамәлдәге | | 72,3651 | - |
| 14 | 70101060 1 | Гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы (урман парклары, парклар, бакчалар, скверлар, бульварлар, шәһәр урманнары) | гамәлдәге | Гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы (урман парклары, парклар, бакчалар, скверлар, бульварлар, шәһәр урманнары) шәһәр паркларын, скверларын, бакчаларын, бульварларын, яр буйларын, шәһәр урманнарын, территорияне төзекләндерү, яссы спорт корылмаларын урнаштыру өчен билгеләнгән яшел утыртмаларны урнаштыру өчен билгеләнгән | 17,1538 | - |
| | | | планлаштырыла торган | | 0,8733 | |
| 15 | 70101060 5 | Урман зонасы | гамәлдәге | Урман зонасы дәүләт урман фонды җирләрен һәм башка категориядәге җирләрдә урнашкан урман кишәрлекләрен урнаштыру өчен билгеләнгән | 160,2080 | - |
| 16 | 70101070 1 | Зиратлар зонасы | гамәлдәге | Зиратлар зонасы зиратлар, крематорийлар һәм җирләү урыннары, шулай ук тиешле гыйбадәт корылмалары урнаштыру өчен билгеләнгән | 29,4911 | - |
| | | | планлаштырыла торган | | 1,0000 | |

| т/с | Зона коды | Функциональ зона исеме | Территорияне үзләштерү характеры | Функциональ зонаны билгеләүнең тасвирламасы | Функциональ зона мәйданы, га | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | 701010702 | Калдыкларны туплау һәм күмү зонасы | гамәлдәге | Калдыкларны җыю һәм күмү зонасы җитештерү һәм куллану калдыкларын, биологик калдыкларны урнаштыру, саклау, күмү, утильләштерү, туплау, эшкәртү, зарарсызландыру өчен билгеләнгән | 0,3775 | - |
| 18 | 701010900 | Акваторияләр зонасы | гамәлдәге | Акваторияләр зонасы табигый яисә ясалма сулык, су агымы яисә суларның даими яисә вакытлыча тупланышы характерлы формаларга һәм су режимы билгеләренә ия булган башка объекттан гыйбарәт | 53,4932 | - |
| 19 | 701011000 | Башка зоналар | гамәлдәге | Башка зоналар функциональ билгеләнеше билгеләнмәгән территорияләрне чагылдыру өчен каралган | 121,2611 | - |
| 20 | 701010703 | Махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр зонасы | планлаштырыла торган | Махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр зонасы санитар саклык, су саклау, саклау-мелиорация зоналарының яшелләндерелгән территорияләрен, автомобиль һәм тимер юллар буенда утыртмаларны, махсус билгеләнештәге башка яшелләндерелгән территорияләрне урнаштыру өчен билгеләнгән | 10,5017 | - |

## 4. Муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителгән очракта территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристика

4.1 нче таблица

**Җир өсте су объектларын саклау чаралары исемлеге**

| т/с | Объектның исеме | Җир өсте су объектларын саклау чарасының төре | Гамәлгә ашыру сроклары | | Чара чыганагы (документ исеме) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Беренче чират | Хисап чоры | |
| 1 | Су саклау зоналары чикләрендәге территорияләр (шул исәптән торак төзелеше) | Агып төшүче суларны рельефка, чистартылмаган агып төшүче суларны су объектларына агызмаска. ВОЗ, ПЗП чикләрендәге торак төзелештәге чокырларның герметиклыгын тикшерергә. ВОЗ чикләрендә транспорт чараларын юуны тыярга. Житештерү һәм куллану калдыкларын су саклау зоналары чикләрендә урнаштыруга юл куймаска. Җирле үзидарә органнары, җирле халык һәм хуҗалык субъектлары көче белән елгаларның су саклау зоналарын куллану калдыкларыннан даими чистартырга. Су саклау зоналары чикләре буенча, зоналарның режимын күрсәтеп, мәгълүмати табличкалар урнаштырырга. | + | - | Россия Федерациясе Су кодексы; СанПиН 2.1.3684-21 «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчә торган суга һәм эчә торган су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак урыннарга, җитештерү, җәмәгать урыннарын эксплуатацияләүгә, санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар оештыруга һәм үткәрүгә санитар-эпидемиологик таләпләр», Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2021 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган. |
| 2 | Су чыгару челтәрләре | Чистарту корылмалары урнаштырырга. Агынты суларны сулыкка агызган очракта, мөмкин булган агызу нормативларын Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белән килештерергә. Агып төшүче суларны су объектына агызу урыныннан 500 м ераклыкта җитештерү контроле. | + | - | Россия Федерациясе Су кодексы |
| 3 | Торак төзелешен үстерү өчен планлаштырыла торган территорияләр | Төзелеш башланганчы Россия Федерациясе Су кодексының 67[1] статьясы таләпләренең үтәлешен, шулай ук әлеге участокларны инженерлык инфраструктурасы челтәрләре белән комплекслы тәэмин итү, шул исәптән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу, аларның санитар саклык зоналарын, урнаштыру урыннарын һәм чистарту корылмаларының куәтләрен (юынтыкларны билгеләнгән нормативларга кадәр чистартуны тәэмин | + | | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | итеп), чистартылган юынтыкларны агызу урыннарын) оештыру белән тәэмин итә торган мәсьәләләрне җентекләп тикшереп, территорияләрне планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерләүне тәэмин итәргә кирәк. | | | |
| 4 | Гамәлдәге һәм планлаштырыла торган торак төзелешләре | Җирле үзидарә органнарына яңа торак төзелеше кишәрлекләрен үзләштерә башлаганчы җирлекнең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программасын эшләргә | + | - | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 27 декабрендәге 1071 номерлы карары белән расланган Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларының I бүлегенең 4 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, муниципаль округларның, шәһәр округларының коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2013 елның 14 июнендәге 502 номерлы карары |

4.2 нче таблица

**Эчә торган су белән тәэмин итү чыганакларын саклау чаралары исемлеге**


| т/с | Объектның исеме | Чараның төре | Гамәлгә ашыру сроклары | | Чара чыганагы (документ исеме) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Беренче чират | Хисап чоры | |
| 1 | Түбән Суыксу авыл җирлегенең артезиан скважиналары | 3 пояс составында санитар саклык зоналары чикләрен КМБДР кертергә.<br>ССЗ поясларының II, III чикләренә әләгүче торак төзелештәге чокырларның герметиклыгын тикшерергә.<br>Агынты суларның рельефка агып төшүенә юл куймаска Беренче поясның тоташ киртәсен төзергә, сак сигнализациясе һәм сак яктырту белән тәэмин итәргә, скважина тамагыннан өске суларны читкә алып китү өчен территорияне планлаштырырга.<br>Эчә торган суның сыйфатына производство контролен тәэмин итәргә.<br>Су корылмалары тарафыннан файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләренә җир асты суларын чыгару өчен җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияләр рәсмиләштерергә | + | - | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибы тарафыннан 2002 елның 26 февралендә расланганСанПиН "Су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы суүткәргечләрне санитар саклау зоналары СанПиН 2.1.4.1110-02" су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклык зоналары проектлары |
| | | Җир асты суларын чыгару максатыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия рәсмиләштерергә.<br>Су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклык зоналары проектларын эшләргә.<br>Скважинаның санитар саклык зоналары проектларын Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белән килештерергә.<br>3 пояс составында санитар саклык зоналарын билгеләргә.<br>Беренче поясның тоташ киртәсен төзергә. ССЗ режимын үтәргә.<br>Скважина тамагыннан өске суларны читкә алып китү өчен территорияне планлаштырырга.<br>Туфрак катламын бозуга бәйле төзелешнең II, III пояслары чикләрендә планлаштырганда Роспотребнадзорның ТР буенча идарәсе белән мәҗбүри килештерү алырга.<br>Эчә торган суның сыйфатына производство контролен тәэмин итәргә. | + | - | |

4.3 нче таблица


**Территориядән файдаланунын махсус шартлары булган зоналарны оештыру чаралары исемлеге**

| т/с | Объектның исеме | ЗОУИТ оештыру буенча чараның төре | Гамәлгә ашыру сроклары | | Чара чыганагы (документ исеме) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Беренче чират | Хисап чоры | |
| 1 | Артезиан скважиналары | Санитар сак зонасы чикләрен билгеләргә һәм КМБДР кертергә. | + | - | Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибы тарафыннан 2002 елның 26 февралендә расланганСанПиН "Су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы суүткәргечләрне санитар саклау зоналары СанПиН 2.1.4.1110-02" |
| 2 | Торак төзелешен үстерү өчен планлаштырыла торган территорияләр | Аларны үзләштерә башлаганчы Россия Федерациясе Су кодексының 67¹ статьясы таләпләре үтәлешен тәэмин итә торган мәсьәләләрне җентекләп тикшереп, территорияләрне планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерләүне, шулай ук әлеге кишәрлекләрне инженерлык инфраструктурасы челтәрләре белән комплекслы тәэмин итүне башкарырга кирәк. | + | - | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы |
| 3 | Аэродром яны территорияләре чикләрендә торак төзелешен үстерү өчен планлаштырыла торган территорияләр | «Бигеш (Түбән Кама)» халыкара аэродромы җитәкчелеге белән килештерергә кирәк. | + | - | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең генераль планы |

ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН НИЖНЕСУЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
КАРТА ПЛАНИРУЕМОГО РАЗМЕЩЕНИЯ ОБЪЕКТОВ
МЕСТНОГО ЗНАЧЕНИЯ
М 1:10000



ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН НИЖНЕСУЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
КАРТА ГРАНИЦ НАСЕЛЕННЫХ ПУНКТОВ
(В ТОМ ЧИСЛЕ ГРАНИЦ ОБРАЗУЕМЫХ НАСЕЛЕННЫХ ПУНКТОВ)
М 1:10000



ГЕНЕРАЛЬНЫЙ ПЛАН НИЖНЕСУЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
КАРТА ФУНКЦИОНАЛЬНЫХ ЗОН
М 1:10000

